**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Аксубай муниципаль районы
Иске Ибрай авыл җирлеге
423078 Иске Ибрай авылы
Кооператив урамы, 2 йорт
тел. (факс) 884344- 4-63-72

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Совет Староибрайкинского
сельского поселения
Аксубаевского муниципального
района
423078 с. Старое Ибрайкино
улица Кооперативная, д.2
тел. (факс) 884344-4-63-72

КАРАР

№ 79

2024 елның 22 марты

**ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Ибрай авыл җирлеге Советының
аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына таянып, федераль законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай Советы

Карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында " 18.07.2019 № 91 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.14 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) әлеге Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләрнең үзенә мәгълүм булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиленең карары буенча үзгәртелгән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр).";

1.2. 34 нче бүлекнең 11 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;";

1.,3. 20 нче бүлекнең 4 нче пункты "мәгълүмат" сүзеннән соң "(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)"сүзләре белән тулыландырылсын;

1.4. 20 нче бүлекнең 3 нче пунктының 2 нче пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелсен:

"2) әлеге Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;";

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubayevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы,
Аксубай муниципаль районы
Иске Ибрай авыл җирлеге
Советы рәисе М.Г.Минигулов